

**…ЧЕ, УСАКИЧҮГӘ КАРА КАРГАЛАР КАЙТТЫ!**

КАРГАСЫЗ НИЧЕК ЯЗ БУЛСЫН? МЕНӘ АЛАР НИҺАЯТЬ КАЙТТЫЛАР, ТЫРЫШЫП ОЯ КОРАЛАР, ТИЗДӘН ТУЙЛАРЫ БАШЛАНАЧАК. ХӘЗЕР УСАКИЧҮНЕҢ ЧИШМӘ БАШЫНДА ҺӘ М ГӘЙНӘ ОЧЫ БОРЫЛЫШЫНДА КАРГА ОЯ КОРА ТОРГАН ӨЯНКЕ, ТУПЫЛЛАРНЫ КҮРМӘССЕҢ, КАРГАЛАР ЧИТТӘРӘК ОЯ ЛЫЙ. Ә МЕНӘ КЕЧЕ ЯШЬТӘН КҮРЕП ҮСКӘН, КАРГАЛАР КАЙНАША ТОРГАН ЯЗЛАР ИСТӘН ЧЫКМЫЙ ГЫНА ТҮГЕЛ, Ә КҮҢЕЛНЕ ЧЕМЕРДӘТЕП КУЯ. ХӘТЕРДӘ УЕЛЫП КАЛГАН ЯЗГЫ АВЫЛ КҮРЕНЕШЕ В.К.САВРАСОВНЫҢ ПОПУЛЯР “КАРГАЛАР КАЙТТЫ” КАРТИНАСЫ ИШЕ ГЕНӘ ТҮГЕЛ. БУ КАРТИНАДА БОРЫНГЫ УРЫС АВЫЛЫНЫҢ КҮҢЕЛСЕЗЛЕГЕ, ТӨССЕЗЛЕГЕ, ЧАРАСЫЗЛЫГЫ ТАСВИРЛАНА. КАРТИНАДАН АЕРМАЛЫ БУЛАРАК, КҮҢЕЛДӘГЕ ЯЗГЫ УСАКИЧҮ “СҮРӘТЕ” ТАБИГАТЬ УЯНУЫ БЕЛӘН БӘЙЛЕ ДӘРТ, ӨМЕТ, ЯШӘҮ КӨЧЕН ТУРЫНДА СӨЙЛИ. КАРГАЛАРНЫҢ ТУКТАУСЫЗ ЫГЫ-ЗЫГЫ, ТАВЫШЛАНУЛАРЫН КҮРЕП КӨЛЕМСЕРӘМИ МӨМКИН ТҮГЕЛ - КЕШЕЛӘРНЕ ХӘТЕРЛӘТӘЛӘР КЕБЕК. БАЛАЧАК СӘХИФӘЛӘРЕНӘ ТАЯНЫП, ЗУРЛАРЧА “ТОРМЫШ ” ДИГӘН САТИРИК ШИГЫРЬ ЯЗЫЛДЫ..

ЛӘКИН КАРГАЛАР КИЛГӘНЕ ТУРЫНДА СӨЕНЕЧ АЛУ БЕЛӘН БӘЙЛЕ ӘЙТӘСЕ КИЛГӘНЕМ БАШКА: КИЛӘСЕ ҖӘЙНЕҢ РӘХӘТЕН КҮРЕРГӘ ЯЗСЫН! КАРГАЛАР ЧЫРКЫЛДАШСА, ЧЫРКЫЛДАР, ҮЗ ЭШЛӘРЕ, САЙРАШЫП ЯШӘП КАЛЫЙК,. ҖӘЙ ЛӘРНЕҢ КАДЕРЕН БЕЛЕП..

ГӨМЕРНЕҢ АГЫШЛАРЫНДА
ҖӘЙЛӘР КИЛӘ ДӘ, КИТӘ
КАДЕРЛЕ МИЗГЕЛ БУЛГАНГА
ҖӘЙЛӘР БИГРӘК ТИЗ ҮТӘ...